# Татар теле

4 класс

- Исәнмесез!
- -Исәнмесез!
- -Хәлләр ничек?
- -Яхшы, рәхмәт.Ә сезнең хәлләр ничек?
- -Бик яхшы, рәхмәт











# Ребус

,, ,,, ы=а ,,



60



Ал

маш

лык

*Дустым Алсу.*

*Минем бик якын дустым бар. Аның исеме - Алсу. Алсу өченче сыйныфта укый. Алсуга 9 яшь. Алсу - бик яхшы укучы. Алсу спортны ярата.*

*Без Алсу белән төрле спорт түгәрәкләренә йөрибез. Мин Алсу белән бик горурланам.*

Дустым Алсу.

Минем бик якын дустым бар. Аның исеме- Алсу. Ул безнең мәктәптә өченче сыйныфта укый. Аңа 9 яшь. Алсу - бик яхшы укучы. Ул спортны ярата. Без аның белән төрле спорт түгәрәкләренә йөрибез. Мин Алсу белән бик горурланам.

# Кабатлыйбыз

- Нинди зат алмашлыклары була?
- Мин-без, син-сез, ул-алар
- Зат алмашлык  җөмләдә нинди сүз төркемен алмаштырып килә?
- Исем
- Зат алмашлыклар нәрсә белән төрләнә?
- Килеш белән.

# Зат алмашлыклары

- Зат алмашлыклары сөйләмдә исемнәрне алмаштыра.

- мин
- 1 нче зат — сөйләүче үзе
- без




- син
- 2 нче зат — тыңлаучы, әңгәмәдәш
- сез




- ул
- 3 нче зат — сөйләүдә катнашмаучы
- алар



# Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше

*Б.к.* *Без* *сез* *алар*

*И.к.* *безнең* *сезнең* *аларның*

*Ю.к* *безгә* *сезгә* *аларга*

*Т.к.* *безне* *сезне* *аларны*

*Ч.к.* *бездән* *сездән* *алардан*

*У-в. к.* *бездә* *сездә* *аларда*

# 77 нче күнегү

1. Бу китап мин__   бар. 2. Укытучы дәрестә син____ сорады. 3. Алар__  йорты яңа һәм зур. 4.Бүген сез__  өй эше бирделәрме? 5.Әлфия без__ кунакка чакырды.

# 77 нче күнегү

1. Бу китап миндә бар. 2. Укытучы дәрестә сине сорады. 3. Аларның йорты яңа һәм зур. 4. Бүген сезгә өй эше бирделәрме? 5.Әлфия безне кунакка чакырды.


# «ЯЛ ИТҮ ПАРКЫ»





# Табышмаклар.

- Берен-бере уза-уза
- Ике туган сызым сыза;
- Ике туган ике якта
- Куя өтер, куя нокта.
- **(Чаңгы һәм аның таяк эзләре)**




- Түп-түгәрәк яссы мин,
- Кышка уен ясыймын:
- Этәләр дә төртәләр-
- Җәтмәләргә кертәләр.
- **(Хоккей алкасы)**



- Утырып шуам аңа:
- Табаннары бик шома.
- Шуам ятып та аңа,
- Нәрсә булыр ул?...
- **(Чана)**



- Килсен бозлы көз генә,
- Ике туган- без генә,
- Йөзне терәп көзгегә,
- Сырлы бизәк-эз генә-
- Төшерәбез тиз генә;
- Тик сыгылма тез генә
- Тота алсын төз генә.
- **(Тимераяклар)**



1. Алмашлык нәрсәне белдерә ?
   а) предметны
   б) эш-хәлне
   в) эш-хәлнең билгесен
   г) исем, сыйфат, сан , рәвеш сүз төркемнәрен алмаштырып килә.
2. Ул дүртенче сыйныфта укый. Ул алмашлыгының нинди җөмлә кисәге булуын билгелә.
   а) ия
   б) хәбәр
   в) хәл
   г) тәмамлык
3. Алмашлык нинди сүз төркеме ?
   а)мөстәкыйль
   б)бәйләгеч
   в)модаль
   г)җөмлә кисәге

4. миңа алмашлыгы нинди килештә килгән?

а) баш килештә

б) төшем килешендә

в) юнәлеш килешендә

г) чыгыш килешендә

5 . зат алмашлыклары нәрсә белән төрләнәләр

а) килеш

б)килеш , сан

в) килеш, сан , тартым

г) килеш, сан , тартым юнәлеш

# Тест җаваплары

*1-г*

*2-а*

*3-а*

*4-в*


*5-б*

# ЗАТ АЛМАШЛЫКЛАРЫНЫҢ МОДЕЛЕ

Зат алмашлыклары
алмаштырып килә
җөмләдә ия
кабатлаулардан коткара

# Кышкы уеннар







# Өй эше

Зат алмашлыкларын кулланып “Кышкы уеннар” дигән темага хикәя язарга.



# Афәрин!!!



***Булдырдыгыз!***